Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XI-3**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 15 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урман фондының җир кишәрлекләреннән һәм су объектлары урнашкан җир кишәрлекләреннән файдаланганда су һәм урман законнарын үтәү турында

Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясенең 2015 елның 30 ноябрендә узган утырышының ПР-355 номерлы беркетмәсенең 1.4 пунктын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урман фондының җир кишәрлекләреннән һәм су объектлары урнашкан җир кишәрлекләреннән файдаланганда су һәм урман законнарын үтәү турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы мәгълүматын игътибарга алырга.

2.Су һәм урман законнарын бозуларны булдырмау һәм җир кишәрлекләре белән эш иткәндә коррупция күренешләрен киметү максатларында:

2.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына урман яисә су объектлары белән территориаль чиктәш җир кишәрлекләрен физик һәм юридик затларга биргәндә, карарлар чыгаруны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы, Федераль су ресурслары агентлыгының Түбән Идел бассейны су идарәсенең Татарстан Республикасы буенча су ресурслары бүлеге, Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы һәм Татарстан Республикасында дәүләт мөлкәте белән идарә итү буенча федераль агентлыкның территориаль идарәсе белән килештерергә;

2.2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре башлыкларына, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең Башкарма комитеты җитәкчесенә тәкъдим итәргә:

2.2.1. урман һәм су фонды җирләре белән чиктәш җир кишәрлекләрен бирүне килештергәндә контрольне көчәйтергә;

2.2.2. урманнарны һәм су саклау зоналарын законсыз файдалануга һәм төзүгә бәйле хокук бозуларны ачыклау өчен халыкны җәлеп итү максатларында “Халык инвентаризациясе” акциясен дәвам итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне экология, табигатьтән файдалану һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев